# КАРАР

“ 18” ноябрь 2021 ел — № 12

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Сеҗе авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 18 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

« Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Сеҗе авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 275 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан ,1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 550 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Мир урамында Кесмәс елгасы аша күпер төзү һәм материаллар сатып алу (2 этап)

-Мәктәп урамыннан 29 нчы йортка кадәр, асфальт юлдан Мәктәп урамының 30 нчы йортка кадәр, Вахитов урамында 7дән 6 нчы йортка кадәр, асфальт юлдан Мир урамы буенча юл-урам челтәренең автомобиль юлларына вак таш җәю;

- асфальт юлдан Школьная урамындагы 24 нче йортка кадәр юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю;
- зиратны карап тоту өчен бензин триммеры (бензокосилка) сатып алу;
- зиратны карап тоту өчен бензопила сатып алу;
- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (борылышлы гидравлик отвал, үзбушаткыч тагылма, чапкыч, фронталь еленмәле төягеч сәнәге, чүмечле фронталь еленмәле төягеч);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ» — “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 191 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 100 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 96 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегендә Сеҗе авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.« Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Сеҗе авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 275 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан ,1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 550 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Мир урамында Кесмәс елгасы аша күпер төзү һәм материаллар сатып алу (2 этап)

-Мәктәп урамыннан 29 нчы йортка кадәр, асфальт юлдан Мәктәп урамының 30 нчы йортка кадәр, Вахитов урамында 7дән 6 нчы йортка кадәр, асфальт юлдан Мир урамы буенча юл-урам челтәренең автомобиль юлларына вак таш җәю;

- асфальт юлдан Школьная урамындагы 24 нче йортка кадәр юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю;
- зиратны карап тоту өчен бензин триммеры (бензокосилка) сатып алу;
- зиратны карап тоту өчен бензопила сатып алу;
- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (борылышлы гидравлик отвал, үзбушаткыч тагылма, чапкыч, фронталь элендерелә төягеч сәнәге, чүмечле фронталь эленмәле төягеч);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ» “КАРШЫ“

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Сеҗе авылы, Мәктәп урамы, 25 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин